**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«21» июль2022 ел Мәләкәс авылы № 11

«Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «агачларның, куакларның авариялелеге турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунтының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзләрен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль район җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алыштырырга;

1.5. 2.6.1 пунктының 6,11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзләрен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль район җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алыштырырга;

1.6. 2.6.3 пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль район җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алыштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктның 2 пунктчасында «яисә яшел утыртмаларны тикшерү нәтиҗәсендә гаризада күрсәтелгән иң чик хәлдә яшел утыртмаларны (аварияле агачларны) бетерү зарурлыгы расланмау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктның 5 пунктчасында «(авария-торгызу эшләрен башкару яки соңгы чик хәлдә яшел утыртмаларны бетерү (агач, авария хәлендәге агачлар аву куркынычын бетерү өчен) белән бәйле очраклардан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4. пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алыштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «, шулай ук авария-торгызу эшләре үткәрү өчен яшел утыртмаларны кисүгә яки соңгы чик хәлдә яшел утыртмаларны бетерү өчен (агач, авария хәлендәге агачлар аву куркынычын бетерү өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3. пунктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5. пунктында «;гариза бирүче авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә соңгы чик хәлдә яшел утыртмаларны бетерү өчен (агач, авария хәлендәге агачлар аву куркынычын бетерү өчен) муниципаль хезмәт алу турында мөрәҗәгать иткән очракта – ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентка 2 нче кушымтада «Авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Ю.П.Васильев